ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.12.2022 г. Заинск № 667

**«Дәүләт торак урыннарын яисә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль торак урыннарын социаль найм шартнамәләре һәм найм шартнамәләре буенча яллап (биләп) торучыларга торак урыннан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 26 ноябрендәге 1758 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешле сыйфат булмаган һәм (яки) тиешле вакыттан артык хезмәт күрсәтүдә өзеклекләр булган очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен торак бинадан файдаланган өчен түләү билгеләүнең методик күрсәтмәләрен раслау турында» 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы (01.07.2022 ел редакциясендә) нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. «Дәүләт торак урыннарын яисә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль торак урыннарын социаль найм шартнамәләре һәм найм шартнамәләре буенча яллап (биләп) торучыларга торак урыннан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 26 ноябрендәге 1758 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган дәүләт торак урыннарын яисә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль торак урыннарын социаль найм шартнамәләре һәм найм шартнамәләре буенча яллап (биләп) торучыларга торак урыннан файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«СРс - социаль наем шартнамәсе һәм наем шартнамәсе буенча бирелә торган дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыны урнашкан Россия Федерациясе субъектында икенчел торак базарында фатирларның гомуми мәйданының 1 квадрат метрының уртача бәясе».

1.2. 2 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль наем шартнамәсе һәм наем шартнамәсе буенча бирелә торган дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыны урнашкан Россия Федерациясе субъектында икенчел торак базарында фатирларның гомуми мәйданының 1 квадрат метрының уртача бәясе Федераль дәүләт статистика хезмәтенең актуаль мәгълүматлары буенча билгеләнә һәм ирекле файдалану мөмкинлеге булган Бердәм ведомствоара мәгълүмати-статистик системада (ЕМИСС) (фатирларның барлык типлары буенча) урнаштырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Зәй муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

А.Н. Симашева
8(85558) 3 13 37